ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«18» 11 2025 г.

**КАРАР**

№ 270

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны кулланучының гарызнамәсе буенча аңа мәгълүмат итеп бирү Тәртибенә үзгәреш кертү хакында**

«Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алуны тәэмин итү турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматка керү мөмкинлеген тәэмин итү турындагы» Федераль законның 10 нчы статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгының 2013 елның 5 апрелендәге 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны кулланучы соравы буенча бирү Тәртибенә, түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1.2.11 пунктның 8 нче абзацында «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләре белән алыштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
район Башлыгы

Р.Р.Нотфуллин